ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШИШИНЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ШЕҢШЕҢӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
«30» января 2020 г.

КАРАР
№ 3

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы карары нигезендә «Татарстан Республикасында Күмү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2020 елның 29 гыйнварындагы 61 нче номерлы карары, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.2020 елның 1 февраленнән Балтач муниципаль районының Шеңшеңәр авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» 2019 елның 28 мартындагы 7 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы» интернет – ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә baltasi.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы: Р.Х.Сәлихҗанов

Шеңшеңәр авыл җирлеге
башкарма комитетының
30 гыйнвар 3 нче номерлы карарына
1-кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге
(01.02.2020 елдан)

| Хезмәтләр исемлеге | Бәясе |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2 Җирләү өчен кирәк булган әйберләр белән тәэмин итү | 2695,27 |
| 3. Үлгән кешенең мәетен (җәсәден) зиратка алып килү | 760,19 |
| 4. Кабер казу һәм җирләү | 2669,4 |
| Барлыгы | 6124,86 |

Шеңшеңәр авыл җирлеге
башкарма комитетының
30 гыйнвар 3 нче номерлы карарына
2-кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге
(01.02.2020 елдан)

| Хезмәтләр исемлеге | Бәясе |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне төрү,киендерү | 232,12 |
| 3. Җирләү өчен кирәк булган әйберләр белән тәэмин итү | 2463,15 |
| 4. Үлгән кешенең мәетен (җәсәден) зиратка алып килү | 760,19 |
| 5. Кабер казу һәм җирләү | 2669,4 |
| Барлыгы | 6124,86 |